وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№10 (205). 4 октябрь 2013 / 28-зөлкагдә-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

# Гакыйдә һәм фикыһта төрле мәзһәбләрнең барлыкка килүе

**Адәм (гәләйһиссәлам) чорыннан алып безнең көннәргә кадәр Аллаһы Тәгалә кешеләрне туры юлга бастыру өчен чиста гакыйдә, яхшы холыклы һәм башкаларга үрнәк булып торучы, Аллаһы Тәгаләдән башка беркемгә дә гыйбадәт кылмаган күп кенә пәйгамбәрләрне җибәргән. Вакытлар узу белән кешеләр, шайтан коткысына бирелеп, Аллаһы Тәгалә белән беррәттән потларга табына башлый, туры юлдан яза.**

Бер яктан, Гайсә (галәйһиссәлам) пәйгамбәрдән соң кешеләр яңадан ширеккә төшә, Гайсә (галәйһиссәлам) пәйгамбәргә Аллаһы Тәгалә сыйфатларын билгелиләр, аны Аллаһы Тәгалә яки Аллаһы Тәгаләнең улы (нәгузүбилләһ) дип атый башлыйлар, икенче яктан - шул вакытта ширек киң таралган Гарәпстан ярымутравында мөшрикләр саны гыйбадәт кылган потларның саны өч йөз алтмышка җитә. Әхлак ягыннан алар бик түбән төшә, алар арасында кыз балаларны тереләтәй күмү, әһәмияте зур булмаган сәбәпләр аркасында кан коюлар киң таралган була.

Бу вакытта Аллаһы Тәгалә Үзенең соңгы пәйгамбәрен - Мөхәммәдне (салләллаһу галәйһи вәссәлам) җибәрә. Ул ширекләре ахыр чиккә җиткән гарәпләр арасында туа. Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) башкалардан өстенлеге, байлыгы булмый, ул өстен катлам кешеләре арасыннан да, сәясәтче яки гаскәр җитәкчеләре арасыннан да булмый. Хак дин тарату юлында да аның Хәдичә (радыяллаһу гәнһәә) исемле хатыны, Зәйд ибне Сабит (радыяллаһу гәнһү) исемле хезмәтчесе, Әбу Талиб исемле абыйсының бик яшь улы Гали ибне Әбу Талиб (радыяллаһу гәнһү) һәм якын дусты Әбу Бакер Әс-Сыйддикътан (радыяллаһу гәнһү) башка бернинди дә булышучылары булмый.

Шуңа да карамастан, яшь Корәеш токымының вәкиле Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) бөтен дөньяга аваз салып, үзенең пәйгамбәр икәнлеген җиткерә. 20 ел эчендә ул үз янына бөтен Гарәпстан ярымутравын берләштерә, тиз арада аның өндәвен дөньяда яшәүче кешеләрнең чиреге кабул итә, һәм бу өндәү бүгенге көнгә кадәр сакланып килә һәм тарала.


Соңрак ислам динен тел, дин, мәдәният һәм гореф-гадәтләре төрле булган халыклар һәм илләр кабул итә. Бу - ислам дине аренасында төрле карашлар килеп чыгуга китерә. Бу барлык диннәр өчен дә гадәти күренеш. Шуңа күрә без, бигрәк тә ислам динендә сәүдәгәрлеккә (тиҗарәткә) караган мәсьәләләрне күрәбез, бу киләчәктә мәзһәбләрнең, гакыйдә һәм фикыһның барлыкка килүенә сәбәп булып тора. Әлбәттә, гакыйдә нигезе булган ысулда башкалыклар кешене мөртәдлек, зиндикълыкка китереп, ислам диненнән чыгара ала, ә фикыһ сорауларындагы һәм аның тармакларындагы башкалыклар кешене бары хатага китерә, ислам диненнән чыгармый.

Һиҗри ел исәбе буенча II гасырда (милади буенча VIII гасыр) "Имам Әгъзам" Әбу Хәнифә Ногман ибне Сабит әл-Күфи (рәхмәтуллаһи галәйһи) пәйда була. Ул 80 нче елда туа һәм 150 нче елда вафат була, шулай ук аның шәкертләре һәм сәхабәләре - "Үсулүд-Дин"гә (гакыйдә-кәлям) һәм "әхкәм" һәм "мүгамәләт"кә (әл-фикъһүль-әхълак) караган "фикер йөрешен" тараткан кешеләр барлыкка килә. Аларның хезмәтләре гакыйдә һәм фикыһ гыйлемнәрендә күренә.

Алар каләме астыннан исламда фикер үсешенә караган гаять күп китаплар чыга. Әбу Хәнифә, аның шәкертләре заманында һәм шулай ук соңрак та гакыйдә буенча төрле фикерләр тарала башлый, гакыйдә эчендә төрле мәзһәбләр барлыкка килә башлый, мәсәлән, мөгътәзилиләр, шигыйлар, рафидыйлар, хариҗиләр, кадәриләр, мүрҗииләр, җәһмиләр, җәбәриләр мәзһәбе һ. б.

Нәкъ менә бу бәхәсләр һәм моназаралар белән тулы заманда, Әбу Хәнифә вафат булганнан соң бер гасыр үткәч, хәлифәлек үзәгеннән еракта, "Мә үәра ән-Нәһр"дә (хәзерге Урта Азия), Сәмәрканд янындагы Мәтүрид җирлегендә имам Әбу Мансур Мөхәммәд ибне Мөхәммәд ибне Мәхмүд әл-Мәтүриди әс-Сәмәрканди туа (261-389 - һиҗри ел исәбе буенча, 875-999 нчы елларда милади буенча).

*(Дәвамы бар.)*



**Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе**

# "ХАҖИЛАРНЫҢ БУРЫЧЫ – АЛЛАҺКА ИХЛАС ТАБЫНУ, Ә БЕЗ ТИЕШЛЕ ШАРТЛАРЫН ТУДЫРЫРБЫЗ"

**Хаҗ - исламның биш баганасының берсе. Ихлас күңелдән хаҗ кылу - кешене Аллаһка якынайта. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хаҗ программасы җитәкчесе Абдулла хәзрәт Галиев "Islam-today" корреспондентына биргән интервьюсында хаҗ сәфәренә баручылар өчен Татарстанда нинди шартлар тудырылуы турында сөйләде.**

*- Хәзрәт, хәзер сезнең хезмәткәрләр өчен бик кызу һәм җаваплы вакыт җитте.*

- Әйе, Аллаһка шөкер! Соңгы атналарда без Татарстанның район вәкилләре катнашында нык эшчәнлек җәелдердек. Казанның Солтан мәчетендә атнаның һәр шимбә һәм якшәмбесендә, өйлә намазыннан соң аларны җыеп укыттык. Бирегә Казаннан һәм аңа якын булган районнардан хаҗ кылырга җыенучылар килә. Дәресләргә чакырылган табиблар хаҗ кылачак мөселманнарга сәламәтлеккә кагылышлы киңәшләрен бирә. Алар, вакытында ясалган прививкаларның, юлда шәхси гигиена таләпләрен үтәүнең мөһимлеген ассызыклый. Хаҗ кылган вакытта күп вакытны аяк өстендә, җәяү йөреп үткәрергә кирәк була. Шуңа да анда киеп бара торган аяк киеме җайлы булырга тиеш. Хаҗ кылучыга, аптечкада булган гади даруларга өстәп, тагын башкалары да кирәк булса, таможня тикшерүен үткәндә проблемалар килеп чыкмасын өчен, аларның рецептлары да булырга тиеш. Безнең хезмәткәрләр таможняда эшләүчеләр белән дә очрашып сөйләште.

Кешенең хаҗ кыла алачакмы-юкмы икәне - Аллаһ ихтыярында. Кызганыч, кайвакыт шулай да була, хаҗ кылырга җыенган кайбер кешеләр, аның хакын түләгәч, кисәк кенә авырып китә я җәрәхәт ала, һәм нәтиҗәдә, изге урыннарга бара алмый кала. Аллаһ аларның изге ниятләрен кылынган гамәл итеп кабул кылсын инде!

*- Сездән хаҗ кылучыларга җитәкчеләр билгеләндеме?*

- Без хаҗ кылучыларны төркемнәргә бүлдек. Һәр 50 кешегә безнең аерым бер вәкилебез җитәкче итеп куелган. Күз алдына китерегез: бер дүрт-биш көн эчендә Әл-Хәрәм

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ТАТАРСТАН ИСЛАМ ИКЪТИСАДЫНДА ҮЗ УРЫНЫН ЯУЛЫЙ

Бу көннәрдә башкалабызда KAZANSUMMIT икътисад форумы эшли. Ислам икътисады һәм финанслары буенча уздырылган конференциядә дөньякүләм танылган белгечләр тәҗрибә уртаклашты, ислам финанслары үсеше турындагы фаразларын җиткерде. Алар фикеренчә, әле ярты гасыр элек кенә күтәрелә башлаган ислам икътисады дөнья икътисадында елдан-ел мөһимрәк урын били бара. Конференциядә билгеләп үтелгәнчә, БДБ илләренең ислам финансларында тоткан урыны әлегә зур түгел. 2018 нче елга ислам финанслары үсеше программасы тормышка ашырылгач, ислам банкы активлары базары БДБ илләрендә 24 миллиард долларны тәшкил итеп, шуның 10 миллиард доллары - Россия, 1 миллиард доллары Татарстан өлешенә туры киләчәк.

### КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИН ИСЛАМ ҮСЕШ БАНКЫНЫҢ ХОСУСЫЙ СЕКТОРНЫ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ИСЛАМ КОРПОРАЦИЯСЕ БАШ ИДАРӘЧЕСЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

2 нче октябрь көнне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Ислам үсеш банкының Хосусый секторны үстерү буенча ислам корпорациясе баш идарәчесе Халед Әл Әбүди (Согуд Гарәбстаны) белән очрашты. Халед Әл Әбүди Россия һәм Ислам оешмасы конференциясенә кергән илләрнең KAZANSUMMIT 2013 - V Халыкара икътисад саммитында катнаша.

Очрашуда мөфти кунакны Татарстан мөфтияте, дини өлкәдәге тенденцияләр, тормышка ашырыла торган яңа проектлар белән таныштырды.

### КАЗАНДА "ХӘЛӘЛ ИНДУСТРИЯ" ФОРУМЫ УЗДЫ

Казанда "EURO-ASIA EXPO 2013" халыкара күргәзмә кысаларында "Хәләл индустриясе" дип аталган форум узды. Форум эшендә катнашу өчен хәләл товарлар житештерүчеләр һәм хезмәт күрсәтүчеләр, предприятиеләр экспертлары, фәнни җәмәгатьчелек һәм дәүләт хакимият вәкилләре чакырулы иде. Ачылышта Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты.

Форумны "Евро-Азия Экспо" җаваплылыгы чикләнгән оешмасы һәм Татарстан мөфтияте карамагындагы "Хәләл" стандарты буенча комитет оештыра.

Форум "Россиядә хәләл индустриясе үсеше тенденцияләре һәм перспективалары" темасын үз эченә ала. Җыенда Россиядә продукцияне читкә чыгару һәм Россиягә чит илдән кертү, "Хәләл" индустриясен Европа - Азия җирлегендә үстерү, дәүләт органнары белән хезмәттәшлек итү, җитештерү технологияләре һәм күзәтчелек мәсьәләләре каралды.

### ТАТАРСТАНДА МӨСЕЛМАН ТУРИСТЛЫК ҮЗӘГЕ ТӨЗЕЛӘ

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга мөселман авылы проектын тәкъдим иттеләр. Әлеге авылны М7 федераль трассасында төзергә ниятлиләр. Мөселман авылында кунакханәләр, мәчетләр, ягулык салу станцияләре, бизнес үзәкләре, мунчалар, һөнәрчелек үрнәкләре сатыла торган урыннар булачак.

Бу проект Татарстанның мөселман туристлык үзәге булырга мөмкин.

## ЯҢАЛЫКЛАР

**КАЗАН ХАҖИЛАРЫ ЮЛГА КУЗГАЛДЫ**

200 хаҗидан торган беренче төркем Казаннан Җиддәгә турыдан-туры рейс белән барып җитәчәк. Аэропортта аларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин озатып калды.

Быел "ДУМ РТ Хадж" программасы ярдәмендә хаҗга баручыларга хаҗилар өчен махсус җыелма тәкъдим ителә. Анда китаплар һәм хаҗ кылыр өчен кирәкле әйберләр, шул исәптән, ир-атлар өчен ихрам киеме дә бар.

**КОРБАН ЧАЛУГА ӘЗЕРЛЕК БАШЛАНДЫ**

Татарстан мәчетләрендә Корбан бәйрәменә әзерлек башланды. Корбан чалдырырга теләүчеләр корбанлык терлек сорап мәчетләргә мөрәҗәгать итә ала. Казан мөхтәсибәтендә белдерүләренә караганда, быел Мәрҗани, Кабан арты, Ризван, Әҗем, Нурислам, Ярдәм, Сөләйман, Хөзәйфә, Ислам һәм башка мәчетләрдә корбанлыклар әзерләнә. Ярдәм мәчете корбан итеп мөгезле эре терлек чалырга теләүчеләрдән генә гаризалар кабул итә.

Казыйлар быел корбан чалу өчен нисабны көмеш бәясеннән хисаплаганда 12 мең сум күләмендә итеп исәпләргә тәкъдим итте.

**ЗӘЙДӘ АГАЧ МӘЧЕТ АЧЫЛА**

Зәй районының Сармашбаш авылында 11 нче октябрьдә яңа мәчет ачыла. Агач мәчет сиксәнгә якын намаз укучыны үзенә сыйдыра ала. Яңа мәчет районда 28 нче иман йорты булачак. Зәйнең үзендә бүгенге көндә биш мәчет эшләп тора.

Мәчет ачу тантанасына нәзарәт, җирлек хакимият вәкилләре, җирлектәге имамнар, авыл халкы чакырулы.

## *АЙНУР АХМӘТШИН:*
# "ЯШЬЛӘРНЕ КЫЗЫКЛЫ ПРОЕКТЛАР БЕЛӘН ҖӘЛЕП ИТӘБЕЗ"

**Бүгенге көндә яшьләрне экстремистик, радикаль дини хәрәкәтләргә иярүдән саклап калу мәсьәләсе шактый кискен тора. Монда аларга дингә дөрес һәм хак юлны күрсәтү бик әһәмиятле роль уйный. Соңгы вакытларда безнең республикабызда бу юнәлештә актив эш алып барыла һәм шуның нәтиҗәсендә уңай үзгәрешләр дә сизелә. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге мөдире, Татарстанның мөселман яшьләре лидеры Айнур Әхмәтшин белән шул хакта сөйләштек.**



*- Республикада "Экстремизмга - юк!" шигаре астында айлык үткәрелүе билгеле. Әлеге айлык кысаларында нинди эшләр башкарыла?*

- Иң беренче чиратта, бу чараның безнең яшьләргә юнәлтелгән булуын һәм аның актуальлеген әйтеп китәргә кирәк. Яшьләргә дини экстремизм һәм радикализм проблемаларын ачыктан-ачык сөйләп, бу проблемаларны бергәләп тикшермәгәндә, аларны безнең илебездәге мөселман өммәтенә хас булмаган радикаль агымнар турында алдан кисәтмәгәндә, нәтиҗәләр аянычлы булырга мөмкин. Игътибар иткәнегез бардыр, төрле илләрдә барган хәрби конфликтлар һәм дини каршы торуларның төп катнашучылары - яшь буын вәкилләре бит. Чөнки аларны үз ягыңа аудару һәм экстремизмга тарту - иң җиңеле.

Ә "Экстремизмга - юк!" шигаре астында үткән айлыкка килгәндә исә, сентябрь аенда берничә мөһим акция үткәрдек. Без бу эшне мәктәпләрдән башладык, төрле яшьтәге мәктәп укучылары белән очрашулар үткәрдек. Аннан соң бу чарага студентларны җәлеп иттек. Әлеге чара кысаларында бизнес һәм эшмәкәрлек буенча зур семинар үткәрелде. Игълан ителгән айлык тематикасы семинар чыгышларында көчле яңгырады.

*- Әле күптән түгел генә футбол буенча традицион турнир узды, белүемчә, ул да сезнең бүлек катнашында үткәрелде бит...*

- Әйе, сентябрь аенда башкалабыз мәчетләренә йөргән яшьләребез арасында үткәргән төп чараларның берсе шул футбол турниры булды. Бу ярышлар да "Экстремизмга - юк!" шигаре астында узды. Турнирда "Мәрҗани-1", "Мәрҗани-2", "Мәрҗани-3", "Кәүсәр", "Ярдәм", "Өмет", "Галиев", "Әниләр", "Зәңгәр" такымнары (командалары) - барлыгы тугыз такым катнашты. Яшьләр арасында спорт ярышлары акциясе үткәргән вакытта без футбол уенын махсус сайлап алдык, чөнки спортның бу төре яшьләр арасында бик популяр.

*- Яшьләрне туплау һәм берләштерүдән тыш, аларны экстремизм куркынычыннан аралауның тагын нинди чаралары бар?*

- Бүгенге көндә төрле дини секталар, радикаль агымнар, милли һәм конфессияара бәхәсләрне күпертергә тырышып эш алып баручылар тарафыннан билгеле бер хәвеф сизелә. Безнең бурыч - яшьләрдә динебезгә, Аллаһы Тәгаләгә, Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде), һәм шулай ук, исламның бөек идеалларын безгә кадәр китереп җиткергән ата-бабаларыбыз васыятьләренә тугрылык хисләре тәрбияләү өчен, барлык тискәре күренешләргә дә каршы тору, аларга каршы лаеклы альтернатива тәкъдим итү. Бу максатка ирешү өчен өч баскыч үтәргә кирәк.

Беренче баскыч - идеология. Безнең динебез - ислам, мәзһәбебез - хәнәфи мәзһәбе, милләтебез - татар. Ул Җир шарындагы иң борынгы милләтләрнең берсе. Безгә менә шул төп ориентирларга йөз тотарга кирәк. Алдыбызда торган иң беренче мәсьәлә - мөселман

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# "ХАҖИЛАРНЫҢ БУРЫЧЫ – АЛЛАҺКА ИХЛАС ТАБЫНУ, Ә БЕЗ ТИЕШЛЕ ШАРТЛАРЫН ТУДЫРЫРБЫЗ"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*




мәчетенең чикләнгән мәйданында миллионнан артык кеше җиде тапкыр Кәгъбәне саубуллашу тәвафы кылырга (урап чыгарга) тиеш. Бу вакытта төркемнең бар кешеләренең дә хәрәкәт итүләрендә тәртип булуы һәм ул хәрәкәтнең ипле, җайга салынган булуы зарур.

*- Бу көннәрдә нәрсә белән шөгыльләнәсез?*

- Хәзерге вакытта без хаҗ кылырга җыенган кешеләрнең күпсанлы шылтыратуларына җаваплар бирәбез. Төркем җитәкчеләре үз төркемнәрендәге хаҗ кылучыларга шылтыратып, аларның хәлләрен белеп тора, саулыклары, кәефләре турында сораша, юлга чыгар алдыннан аеруча әһәмиятле булган мизгелләрне исләренә төшерә, аңлату эшләре алып бара. Сентябрь азагыннан башлап, хаҗ кылучыларны Согуд Гарәбстанына җибәрә башлыйбыз. Аллаһ боерса, октябрь ае башында бу эш төгәлләнер дип торабыз.

*- Сез күрсәткән хезмәтләр арасында нинди яңа төрләре барлыкка килде?*

- Быел без бар хаҗ кылучыларга да кызгылт-сары төстәге кечкенә генә букчалар һәм зур багаж букчаларыннан торган комплектлар тараттык. Бу йөкнең артык булуын, һәм, хаҗга барганда, аннан кайткан вакытта багажларны югалту очракларын кисәтәчәк. Багажга тәгаенләнгән бу букчаларның һәрберсендә дә безнең адрес, телефоннар, электрон адрес күрсәтелгән белешмәләр бар. Алар инглиз телендә язылганнар һәм, әгәр дә багаж ялгыш башка бер илгә озатылса, андагы мөселманнар бу багажны безгә кире җибәрә ала. Аннан тыш, без хаҗ кылучыларның теләкләрен искә алып, аларга рус яки татар телендә "Хаҗ кылуга баручылар өчен сәламәтлек белешмә сүзлеге", "Татарча-русча-гарәпчә сүзлек", Вәлиулла хәзрәтнең кабат бастырылган "Хаҗ һәм гомрә" һәм "Дога" китапларын тәкъдим итәбез. Ул догаларны хаҗ кылган вакытта укырга кирәк. Бишенчесе - Әхмәтһади Максудиның "Гыйбадәте исламия" китабы. Аннан соң, без ир-атлар өчен ихрамнар да бирәбез. Киемнәрне үзебезнең аэропортта ук алыштырырга ниятлибез. Бездән хаҗ кылырга баручылар 12 табиб күзәтүендә булачак.

*- Туклану мәсьәләләре ничек тора?*

- Биш сәгатьлек очу вакытында очкычның бортында ук, хаҗ кылырга баручыларга хәләл ашлар тәкъдим ителәчәк. Булачак хаҗиларны Мәккәдә дә, Мәдинәдә дә, Мина үзәнлегендә дә ике тапкыр ашаталар. Мөздәлифәдә һәм Гарәфәт тавында хаҗ кылучыларга коры паеклар - печенье, хөрмә һәм башка җимешләр, сөт, җирле шартларда җитештерелгән соклар таратачакбыз. Кунакханәләрдә аларга һәрвакыт кайнар чәй һәм каһвә (кофе), шикәр, лимон, коры сөт булачак. Анда якында гына азык-төлек кибетләре дә бар, теләгән кеше кыйммәт булмаган хакка гына алардан ризыклар сатып ала ала. Шуның өчен дә без хаҗ кылырга баручыларга үзләре белән 300-500 доллар акча алырга киңәш итәбез.

*- Хаҗилар кайда яшәячәк?*

- Безнең хаҗилар быел 2012 нче елгы кунакханәдә түгел, ә башка кунакханәдә яшәячәк. Ул бик яхшы кунакханә, Әл-Хәрәмнән чама белән 3-4 чакрымда гына урнашкан. Хаҗилар без алдан сөйләшеп куйган кондиционерлы яхшы автобусларда Әл-Хәрәм мәчетенә бик тиз генә барып җитә алачак. Автобус илтеп куйган җирдән мәчеткә 500 метр гына ара кала. Кунакханәләрдә хаҗилар бер бүлмәдә 4-8 әр кеше, ир-ат һәм хатын-кызлар аерым яшәячәк.

*- Хаҗ кылучыларның якынча саны ничә?*

- Әл-Хәрәм мәчетен реконструкцияләү белән бәйле рәвештә, бар илләргә дә квоталарны киметүгә дә карамастан, бездән меңнән артык кеше хаҗ кылырга бара. Төзекләндерү эшләре тәмамланганнан соң, Согуд Гарәбстаны хөкүмәте вакытлыча киметелгән квоталарны кире өстәп кайтарырга вәгъдә итә.

*- Хаҗ кылучылар Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) мәчетенә һәм Мәдинәдә аның исеме белән бәйле башка истәлекле урыннарга бара алачакламы?*

- Әйе, хаҗ кылганнан соң, без өч көнгә Мәдинәгә барачакбыз һәм андагы истәлекле урыннарда булганнан соң, туры рейс белән Казанга очкычта кайтачакбыз. Хаҗ кылырга баруның сыйфатын яхшырту дигәндә яхшы туклануны, туры авиаочышлар оештыруны күз алдында тотабыз. Хаҗ кылырга барган кешеләр бар мәшәкатьләрдән азат булырга һәм бөтен игътибарларын Аллаһка ихлас табынуга тупларга тиеш. Алар шуның өчен хаҗ кылырга бара бит.

**Фәрид БАТЫРШИН**

## Рөстәм БАТЫР:

# "Без сәяси акыл зәгыйфьлеге һәм дини түзеп торалмаучанлык корбаннары булырга тиеш түгелбез"

### Дини мәсьәләләрне чишүне уйламыйча, күзен йомып карарлар штамплап чыгара торган механизмнар кулына калдырмаска кирәк

**Новороссийск шәһәре Октябрь районы мәхкәмәсенең Эльмир Кулиевның "Коръәни-Кәримнең рус теленә мәгънәви тәрҗемәсе" китабын экстремистик дип табуы турында карар чыгаруы Россиянең мөселман җәмәгатьчелегендә зур реакция уятты. "БИЗНЕС Online" өчен махсус язылган мәкаләсендә Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм Батыр кискен торучы бу мәсьәләгә карата үз позициясен аңлатып кына калмады, ә проблемага киңрәк якын килеп, Россия мөселманнарының бүгенге көндә ничек яшәве мәсьәләләрен дә ачыклап китте.**



#### АННАН ГЫНА ЮАНЫЧ АЗ ШУЛ…

Үткән атнада Россиядә Коръәни-Кәримнең тәрҗемәсен тыйдылар. Моңа ышануы да кыен, әмма бу шулай. "Россия мәхкәмә системасының маразмы чамасыз биеклекләргә җитте", - дип язды бу турыда журналист Максим Шевченко. Аның бу бәяләмәсе белән күп мөселманнар килешә.

Һәр мондый очракта булгандагы кебек, әлеге китапның бөтен ил буенча киләчәген билгеләүче федераль әһәмияткә ия карар бу юлы да ниндидер бер провинциаль шәһәр мәхкәмәсе тарафыннан чыгарылды. Кемдер, Коръән үзе, ягъни аның гарәп телендәге оригиналы түгел, ә Изге Китапның тәрҗемәләренең берсе; хәтта Эльмир Кулиев тәрҗемәсе үзе түгел, ә аның күп сандагы басмаларының аерым берсе генә экстремистик әдәбият исемлегенә кертелгән, дип әйтергә дә мөмкин. Ләкин, бу аргументлар мөселманнарга бик аз юаныч бирә, чөнки бу очракта, ни дисәң дә, Изге Китап тәрҗемәсе турында сүз бара, гәрчә ул бик үк төгәл тәрҗемә булмаса да.

Сүз уңаеннан әйтеп китик, татарлар өчен традицион булган хәнәфи мәзһәбен нигезләүче имам Әбу Хәнифә Коръәннең тәрҗемәләрен кануни караштан чыгып караганда Изге Язманың гарәп телендәге сакраль текстына тиң дип исәпләгән, ә бу исә, башка яклардан тыш, тиешле намазларны туган телеңдә башкару мөмкинлеген дә күз алдында тота. Ләкин, бу караш мөселманнар арасында, шул исәптән Әбу Хәнифә мәзһәбе тарафдарлары арасында да, өстенлек алмаган. Ләкин, бу контекстта шуны әйтеп китү мөһим, Коръәни-Кәримнең гарәп телендәге тексты гына түгел, ә аның һәр тәрҗемәсе, бар мөселманнар өчен дә чиксез зур әһәмияткә ия һәм алар Коръәнгә һәртөрле кул сузуларны бик авыр кичерәләр. Бу әле, Кулиев очрагындагы кебек, тәрҗемәгә карата сораулар тууга һәм аның бер генә төрле аңлашылмый торган автор позициясеннән чыгып язылуына карамастан. Дөресен генә әйткәндә, теләсә нинди тәрҗемәдә дә автор шәхесенең тәэсире булмый калмый.

#### ӘДӘПСЕЗЛЕК ЧИГЕНДӘГЕ ТУПАСЛЫК ...

Бу кадәрле ачу чыгаргыч тыю кабул итүгә мөселманнарның кискен реакциясе үзен озак көттермәде. Интернет меңнәрчә кайнар фикер алышулардан шартлады, ислам форумнары хәзер дә ярсулы ачудан кайнап тора, мөселман лидерлары катгый белдерүләр белән чыгыш ясый, ә ул белдерүләр социаль челтәрләрдә тарала. Бу җәһәттән нигезле бер сорау туа: мондый тыю белән безнең хакимият нәрсәгә ирешмәкче булды да, нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты?

Бу мәхкәмә карарының мотивы, беренче карашка, ачык күренеп тора кебек, ул - дини экстремизм белән көрәш, бу карар, шулай итеп, хәтта яхшы ният белән кабул ителгән дә кебек. Ләкин, "көрәш"нең андый ысуллары шул дәрәҗәдә тупас һәм ипсез, аны әдәпсезлек дип атарга гына кала. Халыкта кайбер хөкемдарлар турында, аларга мөрәҗәгать итү кәҗәне бакчага кертү белән бер, шуңа да, аларны эшкә якын җибәрергә кирәкми, алар эшне тагын да катлауландыра гына, дип юкка гына әйтмиләр бит инде. Бу өлкәдә хөкемдарлар бездән артык нык аерылып торалар дип әйтеп булмый, тик шулай да, аларның аерым бер статуслары бар, димәк, алар өстендәге җаваплылык та күпкә зуррак. Бу вакытта кайбер хөкемдарларның башбаштаклыгыннан аерым бер мөселманнар гына каза күреп калмыйлар, ә юрисдикция тегермәне ташы астына эләккән тагын бик күпләр бу системаның корбаннары була. Дмитрий Медведевның Россия Президенты булган чагында сөйләгән чыгышларының берсе дә экстремистик материалларның федераль исемлегенә керер дип кемнең башына килер иде икән? Әйе, андый факт та булды бездә, зур җәнҗал чыкты, шуннан соң бу карарны яңадан карарга мәҗбүр булдылар. Тик бу факт үзе генә дә, хәзерге юридик системаның, йомшак кына итеп әйткәндә, җитешсезлекләрдән азат түгел икәнлеген күрсәтә.

#### БЕЗ ТАРИХЫБЫЗНЫ НАЧАР ХӘТЕРЛИБЕЗ ҺӘМ ЯХШЫ ТОРМЫШКА БИК ТИЗ ИЯЛӘШӘБЕЗ

Ислам әдәбиятын болай төптән уйламыйча тыю, вөҗдан иреге өлкәсендә соңгы елларда ирешелгән гаять зур казанышларны юкка чыгарырга мөмкин. Беркем дә шул турыда уйланмый: илебез тарихында да мөселманнар әле бервакытта да ул кадәр ирекле түгелләр иде, беркайчан да! Бу патша Россиясе вакытында да юк иде, ул вакытта ислам башта эзәрлекләнә торган, ә Екатерины II дән соң, бары тик түзеп торырга тиешле дин иде, Советлар Союзы вакытында исә дәһрилек режимы бар конфессияләрне дә репрессияләр һәм концлагерьлар богавында тотты. Кайберәүләр: хәзерге Россиядә дә исламга карата барысы да шома гына бармый, кайбер регионнарда хиҗапка, яңа мәчетләр төзүгә каршы көрәшәләр дип тә әйтергә мөмкиннәр. Әйе, бу чынлап та шулай, Татарстанда яшәү бәхете бөтен кешегә дә тәтеми инде. Ләкин, мин кабатлап тагын бер тапкыр әйтәм: мөселманнарның бүгенге көндәге кебек иреге, бу ил тарихында беркайчан да булмады. Һәм без моңа кадәр бервакытта да тигез хокуклылык шартларында яши алмадык. Россия мөселманнарына мөселман булганнары өчен генә хәзер өстәмә салым салынмый, аларның илнең барлык вузларында да укырга, теләсә нинди дәүләт вазыйфасын башкарырга хокуклары бар, ә илдә меңнәрчә мәчетләрнең, йөзләрчә мөселман уку йортларының, сансыз интернет-сайтларның, газеталарның, телетапшыруларның һ. б. эшләп торуын әйтеп тә торасы юк. Кайбер рус милләтчеләре, хәзерге Россиядә титуллы милләт вәкилләре белән чагыштырып караган вакытта, мөселманнар иркенрәк тә яшиләр әле, дип исәпли. Бәлки, бу артык катгый карарга килүдер, тик бу бик симптомистик фикер. Элек Россиядә андый фикерләр бер вакытта да булмаган. Кызганыч, без үз тарихыбызны бик начар беләбез, һәм яхшы тормышка тагын да тизрәк ияләшәбез.

#### МӘХКӘМӘЛӘР КЕМ ТЕГЕРМӘНЕНӘ СУ КОЯ СОҢ?

Югарыда әйтеп кителгәннәр, нигездә, Россиядә де-факто (чынлыкта) милли идея итеп күп халыклардан һәм конфессияләрдән торган бердәм Россия милләте төзүгә ориентир алу белән алшартлана. Гәрчә бу трендка каршы чыгучылар булса да (шул исәптән дәүләт чиновниклары арасында да), ил, тулаем алган вакытта, шул юнәлеш буенча бара. Моның ил һәм регион җитәкчеләренә нинди титаник дәрәҗәдә авырга төшүен бер Аллаһ үзе генә белә. Бу мегапроектны тормышка ашыруның федераль һәм региональ элиталарга күпмегә төшүе бер Сергей Степашинга (ә хәзер аның урынында Татьяна Голикова) билгеледер инде. Сүз уңаеннан: Казан универсиадасын үткәрүне дә шул мегапроектның бер өлеше дип карарга була.

Инде хәзер, күз алдына китерегез, ниндидер бер Урюпинск шәһәрендә исем-фамилиясе беркемгә дә билгесез, исламга каршы комплекслары булган ниндидер бер хөкемдар утыра, ди. Шул хөкемдар 20 миллионлык Россия мөселманнарының күз алдында ислам өммәте өчен илебездә соңгы елларда эшләнгән бар казанышларны үзенең бер култамгасы белән юкка чыгарырга мөмкин ди. Шуннан соң инде, бу илнең төп бурычы - мөселманнарны юкка чыгару дип, Россияне исламга каршы көрәшүдә гаепләү - җиңелнең дә җиңеле. Мондый вакыйгалардан соң, посып яткан почмакларыннан чыгып, илгә төрле сепаратист һәм радикаллар өере агыла башлый, алар Россия дәүләтенең мөселманнарга каршы мәкерле астыртын ниятләре турындагы төрле сафсаталары белән мөселманнарны бу илгә каршы котыртырга тотыналар. Сүз уңаеннан әйтик, гомуммөселман электораль кырында эшләп килүче "Хизб ут-Тәһрир" сәяси фиркасенең Россиягә каршы риторикасында бу илдә ислам әдәбиятын тыю темасы - төп темаларның берсе. Шулай итеп, бозык юрисдикция механизмы кысаларында эшләүче безнең бу мәхкәмәләр, чынлыкта дини экстремизм белән көрәшмиләр, ә аны тудыра һәм үстерәләр генә.

Ә мондый тыюлар тыелган бу әдәбиятның таралуына каршы көрәштә ярдәм итәме соң? Тот капчыгыңны! Былтыр, барысын да гаҗәпкә калдырып, Оренбург шәһәренең бер район мәхкәмәсе "Крепость мусульманина" исемле кесә дога китабын тыйды. Бу тыюның нәтиҗәсе шул - хәзер инде бу китапны "Крепость верующего" исеме астында бастыра башладылар. Көлке! Бу очракта да шулай ук: Новороссийск шәһәренең ниндидер бер район мәхкәмәсе бар Россия өчен Кулиевның бу тәрҗемәсен түгел, ә аның 2002 нче елгы Мәдинә басмасын тыю турында гына карар кабул итте. Бу басма инде, болай да, бернинди мәхкәмә карарыннан тыш та, бик сирәк кенә очрый торган басмага, әдәби раритетка әйләнгән иде. Нәтиҗәдә, әле басмага чамасыз реклама ясалды, элек беркем дә белмәгән бу тәрҗемә бар илгә билгеле булды (тик башка чыганакларда), аны укымаган кеше калмады, хәзер ул инде бөтен интернет буенча сәяхәт итә. Бу тыюдан кем отты соң дип сорыйсы килә. Ә бу сорауга җавап бик гади: бу процесстан Кулиев үзе, одиоз оппозиционерлар һәм сепаратистлар гына отты. Һаман да шул ук тырмага басабыз: яхшы булсын дип эшләгән идек тә, тик бу юлы да һәрвакыттагыча килеп чыкты...

#### "КАРА ИСЕМЛЕК" УРЫНЫНА "АК ИСЕМЛЕК" КИРӘК

Бар бәлаләрдә Россия мәхкәмәләрен генә гаепләү дә бик дөрес үк булып бетмәс. Еш кына алар юридик формальлек корбаннары булып кала. Бу формальлекнең үз мантыйгы бар, ул аның нигезендә чыгарылган карарларның нинди нәтиҗәләргә китерүен игътибарга ала белми. Ләкин, минем белән килешерсез дип уйлыйм, бу формальлек Коръән тәрҗемәләрен һәм Россия Федерациясе Президенты сүзләрен тыю кебек шундый абынуларга китерә икән, димәк, безнең юридик машинабыз төзекләндерүгә мохтаҗ.

Мин үзем, карашларым буенча, бу тәрҗемәнең тарафдары булып тормыйм. Фәнни даирәдәге ислам белгечләренең бу басмага карата мөнәсәбәте дә, дипломатик итеп әйткәндә, бик тыенкы гына. Ләкин, бу вакытта сүз башка әйбер - төрле материалларны экстремистик итеп тану турында бара. Телибезме без моны, юкмы, безнең җәмгыятькә мондый проблемалар белән очрашырга ?ичшиксез туры киләчәк, чөнки, ачыктан-ачык фашистик һәм шовинистик оешмалар бар, ә алар үз идеяләрен формалаштыралар. Шул ук вакытта үз радикальлекләрен дин пәрдәсе артына яшергәннәре дә җитәрлек. Ләкин, миллионнарча кешеләрнең язмышын хәл итә торган мәсьәләләрне чишү - камил булмаган механизм кулында калдырылырга тиеш түгел. Бу система кайчак процесста катнашучыларның гына түгел, ә бөтен ил өчен хәлиткеч әһәмияткә ия булган карарлар кабул итә. Андый дәрәҗәдәге карарлар бөтенләй башка, югарырак дәрәҗәдә, проблеманы белүче экспертларны, кирәк булган очракта традицион конфессияләр белгечләрен дә җәлеп итеп, кабул ителергә тиешләр. Бүтән сүз белән әйткән вакытта, мондый карарга килүләрне җәмәгатьчелек иләге аша үткәрергә кирәк.

Ләкин, экстремизм белән көрәш җәһәтеннән тыелган китапларның "кара" исемлеген төзүгә караганда, киресенчә, рөхсәт, тәкъдим ителгән китапларның "ак" исемлеген төзү күпкә тәэсирлерәк булыр иде. Интернет заманында нәрсәне дә булса тыюның бер мәгънәсе дә юк. Мондый

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# "Без сәяси акыл зәгыйфьлеге һәм дини түзеп торалмаучанлык корбаннары булырга тиеш түгелбез"

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

тыюлар "ау оештырылган ул убырлар"га өстәмә реклама гына бирәләр.

Аның урынына игелеклелекнең якты идеалларын тулысынча чагылдыручы, без җәмгыятебезгә бирергә омтылган ориентацияле хупланган китапларның исемлеген төзү хәерлерәк. Мондый мәсьәләләрне шул исәптән традицион конфессияләр вәкилләреннән башка гына хәл итеп булмау сәбәпле, безгә мантыйкны гына түгел, ә карарлар кабул итү механизмын да үзгәртергә кирәк, ә бу исә тиешле закон инициативалары кертүне таләп итә. Бу механизмда ислам позициясен илебезнең бар мөселманнары өчен дә уртак булган оешма чагылдыра алыр иде, моның өчен ул оешманы төрле Диния нәзарәтләре вәкилләреннән төзергә кирәк.

Дөньяда читтән идарә ителә торган ниндидер "кызгылтмы, яшелме (кем күңеленә нинди төс ошый) яз" сценариен Россиядә дә эшләтеп җибәрергә теләүче көчләр булуын аңлау өчен сәясәт белгече булырга кирәк түгел. Аннан башка гына аларга Россиянең нефть һәм башка ресурсларын кулга төшерү җиңел булмаячак. Ә ул ябышкак чит ил сөлекләренең илне талауларына бездә инде күптән чик куйдылар. Безнең илгә карата андый планнары булуын алар ачыктан-ачык та әйтә башлады инде. Бу уңайдан дини кешеләрнең хисләренә кагылучы андый мәхкәмә карарлары һәм, тулаем алганда, кайбер исламофоб чиновникларның үз борын төпләреннән арыны күрә алмаулары - кайбер геополитик уенчылар өчен күктән төшкән бер бәхет кебек. Алар, безнең күпмилләтле федератив илебезгә күзләрен тозландырып, нәфес белән карап тора. Ә бит нәкъ менә милли-дини фактор ватандашлар сугышы вулканы бәреп чыккан беренче өзеклек сызыгы булып китәргә мөмкин дә.

Без сәяси акыл зәгыйфьлеге һәм дини түзеп торалмаучанлык корбаны булырга тиеш түгелбез. Безгә провинциаль мәхкәмәләрнең дини китапларны тыю практикасына альтернатива эзләргә кирәк. Җәмгыятебезгә мондый мәсьәләләр буенча карарлар кабул итүләрнең юридик механизмын эшләп чыгарырга вакыт. Ул бүгенгесеннән аермалы буларак, гадел, якланганлык, ышанычлылык хисе бирүче; халыкларны таркатучы түгел, ә берләштерүче механизм булырга тиеш. Бу механизм безне уртак Йортта - Россиядә берләштерү өчен хезмәт итәргә тиеш. Ә без бу уртак Йортыбызны безнең илебез, Ватаныбыз булган өчен яратабыз.

"Ватанга мәхәббәт - иманның бер өлеше" сүзләрен безнең мөбарәк Пәйгамбәребезгә адреслыйлар. Коръәни-Кәримнең тәрҗемәсен тыюга кадәр үк имам ән-Нәвавиның Пәйгамбәребез сүзләренең классик җыентыгының тәрҗемәсе дә тыюга эләкте. Әллә инде, Аллаһ рәсүленең алда китерелгән шул сүзләре дә, бездә тиздән экстремистик дип табылыр микән? Кызганыч, ә бит безнең башка Ватаныбыз юк.

***Рөстәм БАТЫР,***
***Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары***

# "ЯШЬЛӘРНЕ КЫЗЫКЛЫ ПРОЕКТЛАР БЕЛӘН ҖӘЛЕП ИТӘБЕЗ"

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

яшьләрен берләштерү, аларны уртак максат һәм омтылышларда туплау.

Икенчесе - дәгъвәт һәм мәгърифәтчелек. Бу юнәлештәге эш төрле мәдәният, мәгърифәт чаралары үткәрү, мәчетләргә йөрүче яшьләр белән эшләүне күздә тота. Бу җәһәттән, үз халкыбызның бай рухый мирасын, халыклар арасында үзара дус һәм тату яшәүнең ата-бабаларыбыздан килгән төп принципларын өйрәнү аерым әһәмияткә ия. Безгә ниндидер чит ил принципларын, шул исәптән төрле шикле агымнарны, үзебезгә алуга зарурлык юк, чөнки, ил тарихында лаеклы үз урыныбыз, игътибарга һәм өйрәнүгә лаек ислам үсеше тарихыбыз бар.

Өченчесе - яшьләрнең социаль активлыгын үстерү һәм аларны бу эшчәнлеккә җәлеп итү. Бу бик мөһим эш, чөнки, социаль проблемаларның мөселман яшьләре тарафыннан хәл ителүе аерым бер мәгънәгә ия. Бу уңайдан, безгә мөселман яшьләре арасында волонтёрлык хәрәкәтен тагын да киңәйтеп җибәрергә кирәк. Бүгенге көнгә республика буенча унөч волонтёрлык отряды оештырылды инде. Алар төрле акцияләрдә катнашып, татарларга хас булган хәйриячелек эшен торгызырга ярдәм итә. Без инвалидларга, ятимнәргә, балалар йортларына, өлкән яшьтәге кешеләргә ярдәм итәбез. Аннан тыш, табигатьне саклау һәм экология буенча да волонтёрлык эшчәнлеге алып барыла.

Тагын бер мөһим нәрсәгә тукталасым килә. Хәзерге вакытта интернетта мәгълүмат шулкадәр күп, исламга яңа аяк атлап керүче яшь кеше андагы тикшерү үтмәгән һәр мәгълүматны чын хакыйкать итеп кабул итәргә, шуның нәтиҗәсендә туры юлдан язарга мөмкин. Шуңа күрә дә, исламны мәчетләрдә, имамнар җитәкчелегендә өйрәнергә кирәк. Һәр дини кешенең үз остазы булырга тиеш. Аннан башка юлдан язуыңны көт тә тор. Миңа моңсу бер вакыйга турында сөйләгәннәр иде. Бер хатын үз улының намазга басуын сорап ике ел буе Аллаһка ялварган. Ләкин аның улы, намазга баскач та, исламны ялгыш аңлап, үзенең әнисен көферлектә гаепләгән. Менә бу инде юлдан язуның ачык бер мисалы. Гомумән, әгәр дә сез таныш булмаган берәрсе белән сөйләшкән вакытта яманатлы, күп чәйнәлгән шул "хәлифәлекләр", "җиһадлар", "кяферләр" турында сүз куертуларны ишетсәгез, андый кешеләрдән читтәрәк тору хәерле, ә алардан дин өйрәнүдән - бигрәк тә. Аларның төп шөгыле - конфронтациягә бару һәм фетнә оештыру.

*- Айнур, мөселман яшьләрен тагын нинди проблемалар борчый?*

- Андый актуаль проблемаларның берсе - наркомания. Ул безнең заманның афәте. Без бу мәсьәлә буенча актив эш алып барабыз. 3 нче октябрьдә Мәрҗани мәчетендә яшьләр клубының чираттагы утырышы шул мәсьәлә буенча үткәрелә. Утырышта врач-нарколог, эксперт, иҗат эшлекләләре катнаша.

*- Якын киләчәктә нинди кызыклы чаралар оештырырга планлаштырасыз?*

- Ниятләгән эшләрдән шуларны әйтергә була: 13 нче октябрьдә "Казан" милли-мәдәни үзәгендә хәләл бизнеска багышланган семинар үткәрәчәкбез, Корбан бәйрәмендә татар яшьләре өчен бәйрәм тантаналары үткәрергә планлаштырабыз, 17 нче октябрьдә Татарстан Эчке эшләр министрлыгының Мәдәният үзәгендә безнең төп бәйрәм чарасы - "Корбан бәйрәме мөбарәк булсын!" концерты үтәчәк, болардан тыш, сукырларны реабилитацияләүнең "Ярдәм" үзәге өчен хәйрия акчасы җыю да оештырылачак. Аллаһка шөкер, безнең чакыруларга сәхнә осталары бик теләп ризалашты, алар арасында Зөһрә Сәхәбиева-Бигичева, Миңгол Галиев, Ильяс Халиков, Булат Нигъмәтуллин һәм башкалар бар.

**Чыганак: www.islam-today.ru**

# Урта Пошалым мәчетен бергәләп төзик!

Хөрмәтле авылдашлар, якташлар, милләттәшләр һәм дин кардәшләр! Аллаһы Тәгалә кушып, Татарстан Республикасының Арча районы Урта Пошалым авылында мәчет төзелә. Халыкта, ил төкерсә, күл була, диләр. Әйдәгез, шушы саваплы эшне бергәләп башкарыйк! Күгебездә тагын бер изге ай калыксын!

Изге гамәлдә матди ярдәм кылырга теләүчеләр өчен, мәхәлләнең Россия Саклык банкындагы исәп-хисап счёты номеры: 42307810262165010034/ 48.

**Корр. счёты номеры: 20202810167000100679.**

Шулай ук, мәчет төзелешенә акчалата ярдәмне авылда (имам-хатыйбка яисә мәхәллә казначеена) калдырып китәргә дә була.

**Элемтә өчен телефон: 89178689729 (Рәшит Галләм).**

# "Мохтаҗларны тукландыр"

**"ЗӘКЯТ"** хәйрия фонды Корбан бәйрәме алдыннан "Мохтаҗларны тукландыр" акциясе башлануын белдерә. Әлеге акция кысаларында фонд мохтаҗларга - авыру кешеләргә, инвалидларга, ялгыз картларга, толларга, ятимнәргә, шулай ук дини уку йортларына өләшү максатыннан, корбан тәкәләре сатып алу өчен акча җыя. Корбанлык тәкәнең бәясе (терлекне чалу, эшкәртү һәм таратуны да кертеп) алты мең сум.

***Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт, 3 нче кат адресы буенча яки +7 (843) 225-33-22 телефоны аша мөрәҗәгать итә аласыз.***

**Интернетта сайтыбыз: www.zakyatrt.ru.**

**Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.**


ЗАКЯТ
БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ФОНД ЦРО ДУМ РТ

# Рәхмәт белдерәбез

Кадерлеләребез Әлфит хәзрәт Җамалетдиновны, Исмәгыйль хәзрәт Гаяновны соңгы юлга озатуда матди һәм рухый ярдәм күрсәткән район җитәкчелегенә, Татарстан мөфтиятенә, мөхтәсибәткә (аеруча Илһам хәзрәткә һәм гаиләсенә), мөселман кардәшләргә, җирле Пенсия фонды идарәсе хезмәткәрләренә, якташларга, дусларга олы рәхмәтебезне белдерәбез. Аллаһы Тәгалә сезне ярдәменнән ташламасын.

**Мәрхүмнәрнең гаиләләре, әти-әниләре, туганнары, якыннары**

# Корбан чалу кемнәргә фарыз?



**Кешегә корбан чалу вәҗиб гамәл дип исәпләнә, әгәр дә:**

1) ул мөселман булса (мөселман булмаганнарга корбан чалу вәҗиб гамәл булып саналмый, чөнки корбан чалу ул - гыйбадәт (Аллаһка табыну));

2) ирекле кеше булса (кол булмаса);

3) авыл яки шәһәрдә даими яшәүче булса (мосафир булмаса);

4) тиешле мөлкәткә ия булган хәлле кеше булса. Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлам) болай дигән: "Тиешле җитеш тормышка (дәрәҗәсенә) җиткән кеше корбан чалсын".

Аллаһның рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәлам) корбан чалу өчен шарт итеп (вәҗиб гамәл итеп) җитеш тормышта яшәүне куйган. "Җитеш тормыш" бу кешедәге байлык күләмен аңлата.

Аның яшәү урынын, җиһазын, кием-салымын, хәрәкәт итү чарасын (автомашина) һәм бу кешенең көндәлек хаҗәтләре өчен кирәк булган башка мөлкәтне исәпләмәгәндә) акчалата бәяләмәсе 200 дирһәм (612,36 грамм) көмеш яки 20 динар (87,48 грамм алтын) бәрабәреннән дә ким булмаган мөлкәт байлык булып исәпләнә.

Зәкятел-фитыр нисабы да байлык булып исәпләнә (мәсәлән, алтын-көмеш әйберләр, банк счётындагы акчалар, сатар өчен әзерләнгән товарлар - болар барысы да - зәкят нисаблары; ә аннан аермалы буларак, сәдакател-фитыр һәм корбан өчен нисаб исәпләгән вакытта тиешле чыгымнардан арткан бар әйберләр дә нисаб исәбенә керә, мәсәлән, сез киеп йөрми торган артык киемнәр һ. б.).

***"Бәдәигүс-санәәигь" һәм "Китәәбүл-Үдъхийәһ" китапларыннан***

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 10 (205) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35419.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 3 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклангыз!**